М.Вахитов исемендәге 2нче гимназиягә -110ел

Секция: «Безнең укучыларыбыз”

# ***Тема:*** *Лениза Вәлиева-безнең укучыбыз, горурлыгыбыз.*

Эшне башкарды: 5б сыйныфы укучылары

Фәнни җитәкче: Валеева Суфия Василовна

Яр Чаллы, 2016ел

29 нчы апрель

# Кереш

Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназияне тәмамлаган укучылар арасында нинди генә дәрәҗәләргә ирешкән, нинди генә танылган кешеләр юк.

Швецов В.А. –Татарстан республикасы вице-премьеры.

Кабардина Н. – велосипед спорты буенча 4 тапкыр бөтендөнья чемпионы.

Шакирҗанов Г.Г. – «Челны – Холод» ААҖ генераль директоры, ТРның азык индустриясенең атказанган хезмәткәре.

Казанцева В. А. – Татарстан Республикасаның халык артисты.

Ганеева К. М. – Чаллы шәһәре санэпедемстанция баш табибы, «Почёт билгесе» орден кавалеры.

Садыйков Ә. Ф. – Шәһәр хәрби комиссарияты җитәкчесе.

Дмитриев В. Д. – Әфганстанда интернациональ бурычын үтәгәндә батырларча һәлак булган каһарман, «Кызыл йолдыз» ордены кавалеры.

Нуруллин И. – Язучы, тәнкыйтьче, галим.

Гатауллин Р. М. – «Балашово» механика заводы директоры, техник фәннәр кандидаты.

Без, 5б сыйныфы укучылары һәм сыйныф җитәкчебез Суфия Василовна белән, үзебезнең фәнни эшебездә менә шушы исемлеккә тагын бер укучыбызны өстәп куярга телибез, чөнки без өйрәнгән гимназия укучысы, бүгенге көндә зур галимә, шагыйрә моңа лаек.

**Фәнни эшебезнең темасы**: “Лениза Вәлиева-гимназиябез укучысы”.

**Эшебезнең максаты:**

1. Вәлиева (Хәбибуллина) Лениза Газинур кызының автобиографиясен өйрәнү;
2. Аны күпяклы шәхес буларак өйрәнү:

а)галимә;

ә)шагыйрә;

3.М.Вахитов исемендәге 2нче гимназияне тәмамлаган укучыбыз-Вәлиева Лениза Газинур кызының иҗатына карата кызыксыну уяту, горурлык хисләре тәрбияләү;

**Эшнең актуальлеге:**

Бу хезмәт актуаль, чөнки гимназия музеенда, тарихында Вәлиева Лениза Газинур кызы турында мәглүмат юк. Ул өйрәнелергә һәм гимназиябезнең 110еллык юбилеен билгеләгән көннәрдә гимназиябез тарихына кертелергә тиеш.

**Төп өлеш**

Вәлиева (Хәбибуллина) Лениза Газинур кызы 1986 елның 14 июлендә Татарстан Республикасының Азнакай шәһәрендә туа. Яр Чаллы шәһәренең М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясендә белем ала (1993–2003). Алабуга дәүләт педагогия университетының татар-рус бүлеген тәмамлый. 2009 елда Казан шәһәренә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына 10.02.02 – Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле) белгечлеге буенча аспирантураның көндезге бүлегенә укырга керә. 2012 елда бөтен төрки дөньяга мәшһүр тел галиме, академик Мирфатых Зәкиевич Зәкиев җитәкчелегендә татар теленең синтаксисы буенча филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә диссертация яклый.

2010-2011 елда Яр Чаллыда Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 2011 елдан бүгенге көнгә кадәр Казан шәһәрендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында фәнни хезмәткәр вазыйфасын башкара.

2008 елда “Диңгездә йолдыз коена” дип аталган беренче шигырь җыентыгы, 2015 елда “Хәят күгем” исемле икенче китабы басылып чыга. Шигырьләре 8 күмәк җыентыкта, “Шәһри Чаллы”, “Көмеш кыңгырау”, “Кама таңнары”, “Мәйдан”, “Идел”, “Сөембикә”, “Ялкын”, “Казан утлары”, “Мәдәни җомга” һ.б. газета-журнал битләрендә дөнья күрә. Шигырьләре рус теленә тәрҗемә ителеп басылып килә (“Идел” журналы (Талия Шарафеева тәрҗемәсе),

Мәскәүдә яшәп иҗат итүче рус шагыйре Виктор Куллэ тәрҗемәсендә “Антология новой татарской поэзии” (2015) җыентыгында. Моннан тыш, фәнни монография (Каузальность в татарском литературном языке. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – 174 с.) һәм Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә (Алтай, Башкортостан, Чувашия, Төмән, Калмыкия, Дагестан, Якутия, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Воронеж һ.б.), Казахтан һәм Төркиядә татар, рус, төрек телләрендә дөнья күргән 50дән артык фәнни мәкалә авторы.

«Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесенең «Поэзия» номинациясендә ике тапкыр I урынга ия була (2011 һәм 2012 елларда).

Вәлиева (Хәбибуллина) Лениза Газинур кызы – филология фәннәре кандидаты, 2014 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Әдәби хезмәтләре

### Төп басма китаплары

Лениза Вәлиева. Диңгездә йолдыз коена / Шигырьләр. – Алабуга: Алабуга шәһәр типографиясе, 2008. – 93 б.

Вәлиева Л.Г. Хәят күгем: шигырьләр / Лениза Вәлиева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 111 б.

### Күмәк җыентыкларда

Вәлиева Л. Тау-кыяда басып торам / Шигырьләр / «Ләйсән» – моңлы бишегебез. Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең 45 еллык юбилее уңаеннан төзелгән күмәк җыентыгы / төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2009. – Б. 205.

Вәлиева Л. Гел «Яр», диеп шашкан булса синең җан / Шигырь / Гаташнамә. Рәдиф Гатауллин-Гаташ иҗаты турында сәхифәләр. Мәкаләләр, эсселар, шигырьләр. – Казан: Матбугат йорты, 2009. – Б. 384.

Вәлиева Л. Шигырьләр / Иделем акчарлагы. Әдәби җыентык: Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар. – Казан: ОМО «Объединение «Отечество», 2010. – Б. 93.

Вәлиева Л. Шигырьләр / Иделем акчарлагы. Әдәби җыентык: Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар. – Казан: ОМО «Объединение «Отечество», 2011. – Б. 26-27.

Вәлиева Л. Шигырьләр / Моң дулкынында: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина. – Чаллы: «Ислам нуры» басмаханәсе, 2011. – Б. 22-28.

Вәлиева Л. Шигырьләр / Иделем акчарлагы. Әдәби җыентык: Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар. – Казан: ОМО «Объединение «Отечество», 2012. – Б. 14-18.

Вәлиева Л. Шигырьләр / Әдәби Чаллы / [төз. Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 440-442.

Лениза Валиева. Стихи / Антология новой татарской поэзии. – М.: «Октябрь», 2015. – 288 с.

**Иҗаты турында**

Гаташ Рәдиф. Яшь йолдыз шигърият яшендәге хыял / Лениза Вәлиева. Хәят күгем: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 3-4.

Гыйззәтуллина К. Әдәби кичә // Шәһри Чаллы. – 2010. – № 305-310 (3719-3724), 24 декабрь. – Б. 12.

Гыйззәтуллина К. Файдасы зур булды / Укучылар белән очрашу // Көмеш кыңгырау. – 2011. – № 3-4 (1524), 15 гыйнвар. – Б. 5.

Лотфуллина И. Лениза Вәлиева: «Шигърият – хис һәм акыл берлеге» / Әңгәмә. Шигырьләр // Шәһри Чаллы. – 2012. – № 98 (3976), 14 декабрь. – Б. 19.

Хәлимов З. «Диңгездә йолдыз коена» / Яңа китап // Шәһри Чаллы. – 2009. – № 15-16 (3115-3116), 21 гыйнвар. – Б. 8.

Хәсәнова Р. Хыяллар канат җәйгәндә / Бәяләмә // Шәһри Чаллы. – 2008. – № 86 (2919), 25 апрель. – Б. 4.

Шәрипов Әнвәр. Сихри нурларга коенган дөнья / Лениза Вәлиева. Диңгездә йолдыз коена / Шигырьләр. – Алабуга: Алабуга шәһәр типографиясе, 2008. – Б. 4-22.

Шәрипов Ә. Язгы җилгә җанны эләм апрель җиткәч // Мәдәни җомга. – 2014. – № 5 (962), 7 февраль. – Б. 16.

Шагыйрәнең яңа китабы (Лениза Вәлиеваның “Хәят күгем” китабы турында) // “Мәдәни җомга”. – 2015. – № 28 (1036), 24 июль. – Б. 14.

Йомгаклау

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә, фәнни эш язу-ул дәвамлы эш, айлар еллар сорый торган хезмәт. Бу хезмәт безнең эшебезнең башы гына әле. Без бу эшне дәвам итәчәкбез,аны тирәнрәк өйрәнербез, киләчәктә аның белән очрашу да үткәрербез дип өметләнеп калабыз.